…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 2 2013. Октябрь
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## Терроризм: ЧИГЕ БУЛЫРМЫ?

**Соңгы вакытларда Россия террорлык актларына бик еш дучар ителә. Метрода шартлаулар, самолётларның авариягә очраулары моңа хәтле дә кабатланып торды, һәм иң куркынычы -халыкның инде бу вакыйгаларга күнегеп килүе. Ләкин фаҗигаләр булып тора, аларны туктату да мөмкин түгел.**

**Россиянең моңа кадәр үз тормышы белән тыныч кына яшәүче Волгоград шәһәре соңгы көннәрдә барлык матбугат чараларында да еш телгә алына. Сәбәп нидә соң?**

**Волгоградта автобуста шартлау булып 32 кеше яраланды. Бу хакта Русия тикшерү комитеты вәкиле Владимир Маркин хәбәр итте. Алар барысы да хастаханәгә салынган. Мәетләр дә бар... Тагы сигез кеше аеруча авыр хәлдә... Ничә гаиләгә сөйләп бетермәслек хәсрәт, югалту ачысы килгән. Бу бит тыныч заманда, беренче сугышлар, афәтләр юк дип торган заманда.Кемгә кирәк бу корбаннар? Ни өчен? Бу корбаннарның якыннарына моны ничек аңлатырга? Ә менә террорлык актларына ни өчен торган саен Россиянең ешрак дучар ителүен, нигә һәр һөҗүм вакытында террористлар белән бергә бер гаепсез кешеләрнең һәлак булуын, һәм башка шундый сорауларга җавапларны һәр кеше үзенчә аңлыйдыр…**

**Ә җавапсыз сораулар бихисап. Һәр яңа көн аларны тудыра гына тора…**

*Рания Газимзянова.9 нчы сыйныф укучысы*

## *ДУМА ЯҢАЛЫКЛАРЫ*

***Атнаның һәр җомгасында укучыларның Дума җыелышы уздырыла. Дума әгъзалары эшләнелгән эшләргә хисап тоталар, яңа атнага план төзиләр. Дума үз эшчәнлеген өч юнәлештә алып бара.***

- ***Экологик культура тәрбиясе формалаштыру;***
- ***Сәламәтлеккә аңлы караш булдыру;***
- ***“Ветеранга булыш!” хәйрия юнәлешендә эшли.***

***Һәр юнәлешнең үз әйдаманы сайлап куела. Аларның эш планнары төзелә. Теләк-тәкъдимнәрегез булса, үз сыйныфыгыздагы Дума әгъзасына җиткерегез, бер генә тәкъдим дә игътибарсыз калмас. Бу атнада Думаның берничә әгъзасы Казанда үзидарә эшчәнлеген оештыру нигезләре буенча кыска уку курслары үтәчәк. Аларга уңышлар телибез. Бик тә мәктәптә укучыларның үзидарәсен җанландырып җибәрәсе иде бит...***

*БУ АЙДА......Октябрь ае мәктәбебез тормышында вакыйгаларга бик ай булды. Ай башында Өлкәннәр көне, бераз соңрак Укытучылар бәйрәме билгеләп үтелде. Һәр ике чарада да укучылар бик актив катнаштылар, бик матур концерт программасы тәкъдим иттеләр. Әлеге эшләрнең төп оештыручысы булган Галия апага рәхмәтебезне җиткерәбез.*

*БУ АЙДА... ”Көзге бал” кичәсе дә бик күңелле булды. Төрле уеннар, дәртле биюләр, шәп дискотека барыбызга да ошады. Тырышсак, булдырабыз бит, җәмәгать!*

*БУ АЙДА... укытучыларыбыз укытуда Сингапур методикасы турында белем алдылар. Үзенчәлекле һәм бик мавыктыргыч бу методиканың кайбер элементлары белән таныша да башладык инде...*

*БУ АЙДА... 9 нчы сыйныф укучылары математика, рус теле һәм татар теленнән мониторинг үттеләр. Шулай ук 5 нче сыйныф укучылары да сынау үттеләр. Нәтиҗәләр түземсезлек белән көтелә.*

*БУ АЙДА... 5нче сыйныф укучылары Варислар сафына кабул ителде. Лаеклы ВАРИСЛАР булуларын теләп калабыз.*

*БУ АЙДА... фән олимпиадаларының мәктәп туры башланды. Үзләре яраткан фәннәрдән укучылар үзара көч сынаштылар, олимпиаданың район турында мәктәп данын яклау өчен иң көчлеләр сайлап алынды.*

*БУ АЙДА... төрле фәннәр буенча чемпионатлар һәм КФУ сайтында интернет-олимпиадалар башланды. Барыгызга да уңышлар телим.*

## ЛАШМАНГА КИЛГӘНГӘ ҮКЕНМИБЕЗ!

Кыңгыраулы мәктәп еллары күңелдә кала торган иң шатлыклы, мәшәкатьсез мизгелләрнең берсе.Мәктәп кешегә бик мөһим булган белемне генә түгел, беренче тормыш дәресләрен дә бирә. Әле кайчан гына 1 нче сыйныфка килгән идек. Беренче укытучы, беренче уңышлар. Туган мәктәп һәм андагы булган шатлыклы һәм моңсу вакыйгалар артта калды, алда - әлегә таныш булмаган яңа тормыш. 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, без сайлау алдында калдык: урта белем алу өчен Лашманга килергәме, әллә башка уку йортын сайларгамы? Без Лашманга килдек. Бу мәктәп, беренче карашка башка мәктәпләрдән әллә ни аерылмыйдыр да. Ләкин монда күңелгә үтеп керә торган җылылык һәм рәхәтлек бар. Бу хисләр мәктәп бусагасын атлап керүгә үк биләп ала. Сыйныф бүлмәләре якты, җылы. Уку өчен бөтен шартлар тудырылган. Укытучыларыбыз да бик ягымлы, сәләтле һәм бик таләпчәннәр. Иң мөһиме – сыйныфыбыз бик тату. 5 авылдан җыелуга карамастан, без бер йодрык сыман – дус, тату. Мәктәп тормышында актив катнашабыз, бер вакыйгадан да читтә калмыйбыз, тырышабыз.

Беренче шикләр инде таралды. Беренче “5”ләләр дәвамлы булды, уңышлардан әлегә баш әйләнмәде. Шулай итеп без Лашман мәктәбен тиз арада үз итеп өлгердек.

Алмаз Галимов. 10 нчы сыйныф.

## ШИГЪРИ ПОЧМАК

*7 нче сыйныф укучысы Алинә Җиһангирова шигырьләр язарга ярата. Сезнең хөкемгә аның берничә иҗат җимешен тәкъдим итәбез.*

**Туган көн.**

Бүген миңа унөч яшь.
Бу торт – сезгә кучтәнәч.
Һич оялып тормагыз –
Әйдәгез, сыйланыгыз!

**Кышның үз кануннары.**

Белмим нигә, дускаем,
Яратам мин кыш аен.
Битемне чеметсә дә,
Аякны өшетсә дә,
Яратам мин кыш аен!

Алинәгә уңышлар телик. Ә шигъри почмакка киләсе санда сезне көтеп калабыз.

## МИНЕМ БУШ ВАКЫТЫМ –МИНЕМ СӘЛАМӘТЛЕГЕМ.

Газетабызда шул исем астында өр-яңа рубрика ачып җибәрәбез. Биредә без буш вакытны ничек итеп үзеңә һәм җәмгыятькә файдалы итеп үткәрү турында сөйләшербез. Беренче язмабызның авторы – 8 нче сыйныф укучысы Зөлфәт Зиннуров.



***Һәр кешенең буш вакыты була. Мин дә андый вакытларымны җилгә очырмас өчен төрле түгәрәкләрдә шөгыльләнеп карадым. Алар арасында минем күңелемә иң хуш килгәне – “Көрәш” секциясе булды. Чын ир-атларны тәрбияли торган әлеге спорт төренә безне биредә укытучыбыз Рафикъ абый Гатин өйрәтә. Аның ярдәмендә мин бик күп төрле көрәш алымнарына өйрәндем. Өйрәнүләр бушка китмәде – без төрле дәрәҗәдәге ярышларда чыгыш ясый башладык. Тиздән “Лашман көрәшчеләре” дигән мактаулы даныбыз да таралды. Хәтерлим: иң беренче ярышта 45 килограммлы үлчәмдә чыгыш ясадым, 3 нче урынны яуладым. Бу минем беренче җиңүем, беренче медалем иде. Бу җиңү мине канатландырып җибәрде, мин көрәш белән тагы да тырышыбрак шөгыльләнә башладым. Бәхеткә, иң якын дусларыма да бу төр спорт ошый иде. Бергә-бергә җиңелрәк тә, кызыклырак та.***

***Көрәш ныклы әзерлек таләп итә. Бер генә мизгел дә онытылып китәргә ярамый, мускулларның көче артсын өчен физик күнегүләр, һәрдаим үлчәвеңне контрольдә тотулар ансат бирелми. Ә җиңәсе килә!!! Җиңү тәме ярыш артыннан ярышка өнди. Мин Аксубай, Норлат, Актаныш, Сарман районнарында зона ярышларында катнаштым, хәтта Казанда республика күләмендә чыгыш ясап, танылган көрәшчеләр белән бер келәмгә бастым. IX спартакиада уеннарында икенче урынга лаек булдым. Авыл сабантуенда да икенче урынны алдым. Әйе, әле минем алга омтылырга мөмкинлегем дә, теләгем дә бар. Камиллекнең чиге юк, диләр бит.***

***Спорт белән шөгыльләэр өчен мәктәптә бөтен шартлар тудырылган. Көрәш өчен махсус келәм, манекеннар да бар. Районыбыз җитәкчелеге дә моңа җитди карый. Безгә махсус форма, аяк киемнәре бирделәр.***

***Минем уңышларыма әти-әнием дә шат. Алар минем көрәш белән шөгыльләнүемә уңай карыйлар, әтием минем белән горурлана, әнием ярышлар вакытында бик борчылып тора, ләкин “яман юлда түгел бит!” – дип үзен тынычландыра. Мин дә аларга үземне аңлаулары өчен рәхмәтле. Остазым Рафикъ абыйга да көрәш дөньясына алып кергәне өчен рәхмәт әйтәсем килә. Шулай ук барлык егетләргә дә “Бер генә минутыгызны да әрәм итмәгез, безнең буш вакытыбыз – ул безнең сәламәтлегебез, безнең уңышларыбыз булсын! Безнең белән барысы да горурлансыннар!” – дип әйтәсем килә.***

**“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015**